| | | |
|---|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 13 сентябрь № 636

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 ел, 1 июнь, 391 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 ел, 1 июнь, 391 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсын үткәрү буенча конкурс комиссиясе составында:

комиссия составыннан А.Л.Анфимованы, Г.А.Нигъмәтуллинны, Ф.М.Хәнифовны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Ренат Вәгыйзь улы Гайнетдиновны | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгын |
| Оксана Алексеевна Кисапованы | Татарстан Республикасы финанс министры урынбасарын |
| Алексей Михайлович Фроловны | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасарын |

| | |
|---|---|
| Гүзәл Азат кызы Шәрипованы | Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасарын. |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 1 июнь, 391 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 сентябрь, 636 нчы карары редакциясендә)

**«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсын (алга таба – Конкурс) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Конкурсның төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасында территориаль иҗтимагый үзидарәләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү;

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре территориясендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз инициативаларын гамәлгә ашыруда халыкның эшлекле һәм социаль активлыгын үстерү һәм стимуллаштыру.

1.3. Конкурсны үткәрүнең бурычлары:

җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен яшәү урыны буенча гражданнарның үзоешуында иң яхшы нәтиҗәләргә ирешкән территориаль иҗтимагый үзидарәләрне билгеләү;

территориаль иҗтимагый үзидарәнең уңай тәҗрибәсен билгеләү һәм бүлешү.

1.4. Конкурсны оештыру һәм үткәрү эше түбәндәге принципларга нигезләнә:

гавами һәм ачык булу;

Конкурста катнашучыларның тигезлеге;

Конкурста катнашучылар хәл итә торган мәсьәләләрнең социаль әһәмиятлелеге.

1.5. Конкурсны үткәрү шарты булып тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында алда әйтелгән максатларга күздә тотылган ассигнованиеләр булуы тора.

1.6. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр файдаланыла:

грант – Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәләрен бүләкләү максатларында, Конкурс йомгаклары буенча бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы;

заявка – Конкурста катнашу өчен кирәкле документлар исемлеге;

катнашучы – Конкурсның I этабында катнашуга заявка тапшырган Татарстан Республикасының территориаль иҗтимагый үзидарәсе;

дәгъвачы – Конкурсның II этабында катнашуга заявкасы кабул ителгән Татарстан Республикасының территориаль иҗтимагый үзидарәсе;

вәкаләтле органнар – Татарстан Республикасы муниципаль районнарының

(шәһәр округларының) башкарма комитетлары;

Конкурста җиүчеләр – Конкурста I, II һәм III урыннар алган Татарстан Республикасының территориаль иҗтимагый үзидарәләре;

Конкурста призлы урын алучылар – Конкурста IV һәм V урыннар алган Татарстан Республикасының территориаль иҗтимагый үзидарәләре;

территориаль иҗтимагый үзидарә активы – территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегендә актив катнашучы халык.

## II. Конкурсны үткәрү комиссияләрен формалаштыру һәм аларның эшчәнлеге тәртибе

2.1. Конкурсны үткәрү максатларында Конкурсны үткәрү буенча конкурс комиссиясе (алга таба – Конкурс комиссиясе) һәм Конкурсны үткәрү буенча муниципаль конкурс комиссияләре (алга таба – муниципаль конкурс комиссияләре) төзелә.

2.2. Конкурс комиссиясе Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе (алга таба – Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы) вәкилләреннән формалаштырыла.

Конкурс комиссиясе составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

2.3. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда исемлек составындагы әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы була.

2.4. Конкурс комиссиясе карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр алар өчен утырышта катнашучы Конкурс комиссиясе әгъзаларының 50 процентыннан күбрәге тавыш бирсә, кабул ителгән булып санала. Тавышлар тигез булган очракта, Конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч була.

2.5. Конкурс комиссиясе карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә һәм Конкурс комиссиясе утырышын үткәргән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Конкурс комиссиясе рәисе һәм әгъзалары тарафыннан имзалана.

Конкурс комиссиясе беркетмәләре аларны имзалаган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

2.6. Муниципаль конкурс комиссияләре вәкиллекле һәм башкарма җирле үзидарә органнары, сәяси партияләр, җәмәгатьчелек вәкилләреннән формалаштырыла.

Территориаль иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләре муниципаль конкурс комиссияләре әгъзалары була алмый.

Муниципаль конкурс комиссиясе составын һәм эш регламентын, әлеге Нигезләмәне исәпкә алып, вәкаләтле орган раслый.

2.7. Конкурс комиссиясе һәм муниципаль конкурс комиссияләре карарларына катнашучылар һәм дәгъвачылар законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерә ала.

## III. Конкурсны оештыру һәм аны үткәрү тәртибе

3.1. Территорияләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләр эшләп килгән муниципаль берәмлекләр әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымта нигезендә өч конкурс төркеменә бүленә:

I төркем – шәһәр округлары;

II төркем – халкы саны 60 мең кешедән артык булган шәһәр җирлекләре;

III төркем – халкы саны 60 мең кешедән әзрәк булган шәһәр җирлекләре һәм авыл җирлекләре.

Конкурста җиңүчеләр һәм призлы урын алучылар һәр конкурс төркеме буенча аерым билгеләнә.

3.2. Конкурс ике этапта үткәрелә.

I этап (муниципаль) муниципаль конкурс комиссияләре тарафыннан үткәрелә.

II этап (республика) Конкурс комиссиясе тарафыннан үткәрелә.

3.3. Конкурста катнашуга уставлары «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, ФЗ-131 нче Федераль законның 27 статьясы нигезендә теркәлгән, шулай ук эшчәнлекләрен Конкурсны игълан иткән көнгә кадәр кимендә бер ел Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра торган территориаль иҗтимагый үзидарәләр кертелә.

3.4. Конкурсны игълан итү, Конкурсның I һәм II этапларын үткәрү вакытлары турындагы карарны (алга таба – карар) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы кабул итә.

3.5. Конкурсның I этабында катнашуга заявкалар кабул итү турында мәгълүмати хәбәр Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында карар кабул иткән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә, ләкин зявкаларны кабул итү вакыты башланганга кадәр өч календарь көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

Конкурсның I этабында катнашуга заявкаларны кабул итә башлау һәм кабул итүне тәмамлау вакытлары;

Конкурсның I этабында катнашуга заявкаларны кабул итү вакыты һәм урыны, муниципаль конкурс комиссиясенең почта һәм электрон адреслары;

заявкаларны әзерләү мәсьәләләре буенча консультация алуга элемтә өчен телефоннар.

3.6. II этапта катнашуга заявкалар кабул итү турында мәгълүмати хәбәр Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында карар кабул иткән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә, ләкин зявкаларны кабул итү вакыты башланганга кадәр өч календарь көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

Конкурсның II этабында катнашуга заявкаларны кабул итә башлау һәм кабул итүне тәмамлау вакытлары;

Конкурсның II этабында катнашуга заявкаларны кабул итү вакыты һәм урыны, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советының почта һәм электрон адреслары;

заявкаларны әзерләү мәсьәләләре буенча консультация алуга элемтә өчен телефоннар.

3.7. Конкурсның I этабында катнашуга заявка түбәндәгеләрне үз эченә ала:

әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасына ярашлы рәвештәге форма буенча Конкурста катнашу турындагы гаризаны;

әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасына ярашлы рәвештәге форма буенча территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге турындагы мәгълүматны.

Заявка турыдан-туры Конкурсның I этабы үткәрелә торган урынга тапшырыла.

3.8. Муниципаль конкурс комиссияләре заявкаларны кабул итү вакыты башланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Конкурсның I этабында катнашуга заявкаларны кабул итүне һәм теркәүне гамәлгә ашыра.

3.9. Муниципаль конкурс комиссияләре заявкаларны кабул итү тәмамланган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 4 нче кушымтадагы критерийлар нигезендә конкурсның I этабында катнашуга тәкъдим ителгән заявкаларны бәяләүне гамәлгә ашыра һәм вәкаләтле орган билгеләгән тәртиптә Конкурсның II этабында катнашуга дәгъва кылган катнашучыларны билгели.

3.10. Муниципаль конкурс комиссияләре Конкурсның I этабын үткәрү нәтиҗәләре буенча Конкурсның II этабына түбәндәгеләрне кертә:

аның нигезендә муниципаль конкурс комиссиясе төзелгән һәм составы расланган муниципаль хокукый акт күчермәсе;

Конкурсның I этабында барлык катнашучылар исемлеге;

муниципаль конкурс комиссиясе рәисе имзалаган муниципаль конкурс комиссиясе утырышының йомгак беркетмәсе;

Нигезләмәнең 3.9 нчы пункты нигезендә конкурсның II этабында катнашуга дәгъва кылучы катнашучылар заявкалары.

3.11. Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары Конкурсның II этабында катнашу өчен дәгъва кылучыларның заявкаларын әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтада билгеләнгән саннан арттырмыйча җибәрә.

3.12. Конкурсның II этабында катнашуга заявкалар кабул итү заявкаларны кабул итү вакыты башланган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла. Заявкаларны кабул итү һәм теркәүне Конкурс комиссиясе каршында биш кешелек составта төзелә торган эшче төркем гамәлгә ашыра. Эшче төркем составы Конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан раслана.

3.13. Конкурс комиссиясе Конкурсның II этабында заявкаларны кабул итү тәмамланган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 4 нче кушымтада китерелгән заявкаларны бәяләү критерийлары нигезендә баллар системасы буенча катнашуга тәкъдим ителгән заявкаларны бәяли.

3.14. Заявкаларны бәяләү нәтиҗәләре Конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы тарафыннан әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 5 нче кушымтадагы форма буенча тутырыла торган заявкаларны бәяләү кәгазенә кертелә. Конкурс комиссиясенең барлык әгъзалары тарафыннан бөтен критерийлар буенча куелган баллар суммасы дәгъвачының йомгак бәяләмәсен тәшкил итә. Конкурста катнашуга заявкаларның

йомгак бәяләмәсе нәтиҗәләре әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 6 нчы кушымтада китерелгән формага кертелә.

Бәяләү йомгаклары буенча баллар кими торган тәртипә дәгъвачылар рейтингы төзелә.

3.15. Конкурс комиссиясе Конкурста җиңүчеләрне һәм призлы урын алучыларны билгели һәм әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 7 нче кушымта нигезендә, һәр дәгъвачы үз төркемендә җыйган балларның йомгак суммасынна чыгып, грантларны бүлә.

3.16. Грант фонды күләме ел саен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләреннән чыгып билгеләнә.

3.17. Грантларның күләмнәре түбәндәгеләрне тәшкил итә:

I урын өчен – 665,0 мең сумнан артык түгел, шул исәптән устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм социаль әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә – 608,0 мең сумнан артык түгел, территориаль иҗтимагый үзидарә рәисен бүләкләүгә – 28,5 мең сумнан артык түгел, территориаль иҗтимагый үзидарә активын бүләкләүгә – 28,5 мең сумнан артык түгел;

II урын өчен – 500,0 мең сумнан артык түгел, шул исәптән устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм социаль әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә – 455,0 мең сумнан артык түгел, территориаль иҗтимагый үзидарә рәисен бүләкләүгә – 22,5 мең сумнан артык түгел, территориаль иҗтимагый үзидарә активын бүләкләүгә – 22,5 мең сумнан артык түгел;

III урын өчен – 430,0 мең сумнан артык түгел, шул исәптән устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм социаль әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә 395,0 мең сумнан артык түгел, территориаль иҗтимагый үзидарә рәисен бүләкләүгә – 17,5 мең сумнан артык түгел, территориаль иҗтимагый үзидарә активын бүләкләүгә – 17,5 мең сумнан артык түгел;

IV урын өчен – 298,0 мең сумнан артык түгел, шул исәптән устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм социаль әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә – 270,0 мең сумнан артык түгел, территориаль иҗтимагый үзидарә рәисен бүләкләүгә – 14,0 мең сумнан артык түгел, территориаль иҗтимагый үзидарә активын бүләкләүгә – 14,0 мең сумнан артык түгел;

V урын өчен – 160,0 мең сумнан артык түгел, шул исәптән устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм социаль әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә – 145,0 мең сумнан артык түгел, территориаль иҗтимагый үзидарә рәисен бүләкләүгә – 7,5 мең сумнан артык түгел, территориаль иҗтимагый үзидарә активын бүләкләүгә – 7,5 мең сумнан артык түгел.

3.18. Үз конкурс төркемендә иң күп баллар суммасы җыйган дәгъвачыларга «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» исеме бирелә һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы дипломнары тапшырыла.

3.19. Конкурсның II этабында I, II һәм III урыннар алган Конкурс җиңүчеләре йомгаклары буенча алар җиңүчеләр дип танылган Конкурсны үткәргәннән соң кимендә ике ел үткәч кенә Конкурста катнашучылар була ала.

3.20. Конкурста катнашу өчен тапшырылган заявкалар рецензияләнми һәм кире

кайтарылмый.

## IV. Грантлар бирү тәртибе

4.1. Грантлар бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан территорияләрендә Конкурста җиңүчеләр һәм призлы урын алучылар дип танылган территориаль иҗтимагый үзидарәләр теркәлгән муниципаль берәмлекләр бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасының бюджеты турында Татарстан Республикасы законында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә күчерелә.

Башка бюджетара трансфертлар акчасын бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

4.2. Территорияләрендә Конкурста җиңүчеләр һәм призлы урын алучылар дип танылган территориаль иҗтимагый үзидарәләр теркәлгән вәкаләтле органнар, Конкурс комиссиясе утырышының беркетмәсе Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советының рәсми сайтында урнаштырылган көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы белән расланган форма буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән Конкурста җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга грантлар бирү турында шартнамә (алга таба – шартнамә) төзи.

4.3. Вәкаләтле органнар Конкурста җиңүчеләр һәм призлы урын алучылар дип танылган территориаль иҗтимагый үзидарәләргә грантлар бирүгә башка бюджетара трансфертлар акчасын җибәрергә тиеш.

4.4. Грант түләүгә бирелгән акчадан максатчан файдаланмау һәм (яки) дөреслеккә туры килмәгән хисаплылык тапшыру ачыкланган очракларда грантларны түләүгә бирелгән акча Татарстан Республикасы бюджеты керемenә 60 көн эчендә кайтарылырга тиеш.

Грантлар түләүгә бирелгән акчаны кайтару вакытын бозган очракта, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән вакыттәмамланганнан соң 30 көн эчендә күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнарда билгеләнгән тәртиптә кире кайтару буенча чаралар күрә.

4.5. Грантларны түләүгә бирелгән акчадан максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында, вәкаләтле органнар хисап елыннан соң килә торган елның 1 июленә кадәр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына әлеге акчадан файдалану турында финанс хисабы тапшырырга тиеш.

4.6. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы вәкаләтле органнарның грантларны түләүгә бирелгән акчаны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен саклавын тикшерүне законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

4.7. Грантларны түләүгә бирелгән акчадан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан гамәлдәге законнар нигезендә башкарыла.

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта

**Территорияләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләр эшли торган муниципаль берәмлекләрнең конкурс төркемнәре**

| Төркемнәр | Муниципаль берәмлек исеме | 2016 елның 1 гыйнварына территориаль иҗтимагый үзидарәләр саны | Заявкаларның максималь саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| **I төркем – шәһәр округлары** | Казан шәһәре | 51 | 26 |
| | Чаллы шәһәре | 65 | 33 |
| | **Барлыгы** | **116** | **59** |
| **II төркем – халкы саны 60 мең кешедән артык булган шәһәр җирлекләре** | Әлмәт шәһәре | 36 | 18 |
| | Бөгелмә шәһәре | 4 | 2 |
| | Алабуга шәһәре | 8 | 4 |
| | Зеленодольск шәһәре | 4 | 2 |
| | Лениногорск шәһәре | 13 | 6 |
| | Түбән Кама шәһәре | 26 | 13 |
| | Чистай шәһәре | 8 | 4 |
| | **Барлыгы** | **99** | **49** |
| **III төркем – халкы саны 60 мең кешедән әзрәк булган шәһәр җирлекләре һәм авыл җирлекләре** | Әгерҗе шәһәре | 4 | 2 |
| | Азнакай шәһәре | 13 | 6 |
| | Азнакай муниципаль районы составына керә торган Актүбә штп. | 4 | 2 |
| | Арча шәһәре | 5 | 3 |
| | Баулы шәһәре | 4 | 2 |
| | Бөгелмә муниципаль районы составына керә торган Карабаш штп. | 1 | 1 |
| | Буа шәһәре | 6 | 3 |
| | Алабуга муниципаль районы составына керә торган Танай, Костенеево авыл җирлекләре | 2 | 1 |
| | Зәй шәһәре | 6 | 3 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | Зеленодольск муниципаль районы составына керә торган Васильево штп., Карамалы Тау штп. | 4 | 2 |
| | Аксубай муниципаль районы составына керә торган Иске Илтерәк авыл җирлеге | 5 | 3 |
| | Кама Тамагы муниципаль районы составына керә торган барлык шәһәр һәм авыл җирлекләре | 20 | 10 |
| | Кукмара муниципаль районы составына керә торган Кукмара штп. | 4 | 2 |
| | Лаеш муниципаль районы составына керә торган Лаеш шәһәре, Столбище, Габишево авыл җирлекләре | 7 | 4 |
| | Мамадыш муниципаль районы составына керә торган Мамадыш шәһәре, Красногорский авыл җирлеге | 15 | 8 |
| | Менделеевск шәһәре | 5 | 3 |
| | Минзәлә шәһәре | 5 | 3 |
| | Түбән Кама муниципаль районы составына керә торган Кама Ааны штп. | 2 | 1 |
| | Яңа Чишмә муниципаль районы составына керә торган Яңа Чишмә авыл җирлеге | 1 | 1 |
| | Нурлат муниципаль районы составына керә торган Нурлат шәһәре, Мамык, Төрнәс авыл җирлекләре | 13 | 6 |
| | Болгар шәһәре | 1 | 1 |
| | Тәтеш шәһәре | 5 | 3 |
| | **Барлыгы** | **132** | **70** |
| **Барысы** | | **347** | **178** |

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта

Форма

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында катнашу турында
ГАРИЗА

______________________________________________________________________
(территориаль иҗтимагый үзидарә уставының исеме, аны теркәү көне)
______________________________________________________ нигезендә эш итүче
__________________________________________________________________
____________________________________________________________ йөзендә
(территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчесе)
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(территориаль иҗтимагый үзидарә исеме)

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында катнашырга теләүләрен белдерәләр һәм __________ елга территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге турында мәгълүмат тапшыралар.

Заявканы имзалаган территориаль
иҗтимагый үзидарә җитәкчесенең
вазыйфасы исеме

___________________________________

Ф.И.Ә.И. ___________________________

___________________________________
(имзасы)
«_____»____________ 20___ ел

М.У. (булган очракта)

Заявканы
кабул итү көне:
Заявка номеры:

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымта

Форма

**Татарстан Республикасы _____________________**
**муниципаль районының (шәһәр округының)**
**территориаль иҗтимагый үзидарәсе эшчәнлеге турында мәгълүмат**

## I. ТИТУЛ БИТЕ

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Территориаль иҗтимагый үзидарә исеме | |
| 2. | Территориаль иҗтимагый үзидарә урнашкан урынның адресы | |
| 3. | Территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчесенең Ф.И.Ә.И. һәм вазыйфасы | |
| 4. | Кәрәзле телефоны | |
| 5. | Эш телефоны, факс | |
| 6. | E-mail | |
| 7. | Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру көне | |
| 8. | Конкурс турында нинди чыганактан белдегез (массакүләм мәгълүмат чарасыннан булса, исемен күрсәтегез) | |

Әлеге белешмәләр белән тапшырылган мәгълүматның дөреслеген һәм «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында катнашырга әзер булуыбызны раслыйбыз.

Территориаль иҗтимагый үзидарә
җитәкчесе ______________________ _________________________________
(имзасы) (имзаның аңлатмасы)
«___» ___________ 20__ ел.

М.У. (булган очракта)

## II. ГОМУМИ БЕЛЕШМӘЛӘР

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Мәгънәсе |
|---|---|---|
| Йортлар саны | | |
| Урамнар саны | | |
| Территориаль иҗтимагый үзидарә советы әгъзалары саны | кеше | |
| Территориаль иҗтимагый үзидарә территориясендә яшәүчеләр саны | кеше | |
| Чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территория мәйданы | кв.метр | |

## III. ТЕРРИТОРИАЛЬ ИҖТИМАГЫЙ ҮЗИДАРӘ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ ТАСВИРЛАМА

(агымдагы һәм үткән елларга)

Барлык формалар электрон рәвештә тутырыла. Кулдан тутырылган формалар Конкурста катнашуга кертелми.

Әлеге бүлекнең күләме 5 биттән артмаска тиеш.

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Территориаль иҗтимагый үзидарә территориясендә яшәүче халык белән эшләү ни рәвешле оештырылганын тасвирлагыз | Үткәрелгән җыелышлар, советлар, конференцияләр һәм башкалар саны һәм аларда карап тикшерелә торган мәсьәләләр. Санап үткән чараларның нәтиҗәлелеге |
| 2. | Территориаль иҗтимагый үзидарә территориясендә яшәүче граждан-нарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү ни рәвешле оештырылганын тасвир-лагыз | |
| 3. | Төрле дәрәҗәдәге хакимият орган-нарына территориаль иҗтимагый үзидарә башлангычы буенча әзерләнгән тәкъдимнәр (тәкъдимнәр санын күрсәтеп) һәм әлеге тәкъдимнәр буенча эш нәтиҗәләре | |

| | | |
|---|---|---|
| 4. | Территориаль иҗтимагый үзидарәнең төрле дәрәҗәдәге хакимият органнары белән үзара хезмәттәшлеге ни рәвешле оештырылганын һәм территориаль иҗтимагый үзидарә әгъзаларының төрле дәрәҗәдәге хакимият органнары каршындагы киңәшмә органнары эшчәнлегендә ни рәвешле катнашуларын тасвирлагыз | Киңәшмә органнары очрашулары саны һәм аларда карап тикшерелә торган мәсьәләләр. Санап үткән чараларның нәтиҗәлелеге |
| 5. | Территориясендә эшли торган төрле милек формаларындагы оешмалар белән территориаль иҗтимагый үзидарәнең үзара хезмәттәшлеге ни рәвешле оештырылганын күрсәтегез | Социаль яклау учреждениеләре, Россия Федерациясе Пенсия фондының тиешле бүлекләре, иҗтимагый оешмалар, идарә итүче компанияләр, яшәү урыны буенча белем бирү оешмалары һәм яшүсмерләр-яшьләр клублары, коммерциячел компанияләр, индивидуаль эшмәкәрләр һ.б. белән хезмәттәшлек ничек оештырылганын тасвирлагыз |
| 6. | Территориаль иҗтимагый үзидарәнең эшчәнлеген тасвирлагыз | Территориаль иҗтимагый үзидарәнең эшчәнлеген түбәндәге юнәлешләр буенча тасвирларга кирәк: физик культура һәм спортны үстерү, ялны һәм массакүләм ялларны оештыру, гражданнарның аерым категорияләренә ярдәм күрсәтү, тарихи һәм мәдәни мирасны саклау, туристлыкны үстерү, территорияне төзекләндерү, иҗтимагый контроль, табигатьне саклау, экологик куркынычсызлык һ.б. Аеруча әһәмиятле чараларның конкрет мисалларын китерегез һәм нинди нәтиҗәләргә ирешә алганыгызны күрсәтегез |

| | | |
|---|---|---|
| 7. | Территориаль иҗтимагый үзидарәнең үз эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бюджеттан тыш акча җәлеп итү буенча эш тәҗрибәсен күрсәтегез | Территориаль иҗтимагый үзидарәнең нинди чыганаклардан, нинди күләмнәрдә һәм нинди эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бюджеттан тыш акча җәлеп итүен, әлеге чараларның территориаль иҗтимагый үзидарәгә нинди формада бирелүен тасвирлагыз |
| 8. | Территориаль иҗтимагый үзидарәнең үз эшчәнлеген һәм казанышларын ни рәвешле яктыртуын тасвирлагыз | Массакүләм мәгълүмат чараларындагы басмалар күчермәләрен, интернет-ресурсларга сылтамаларны һ.б. теркәгез |
| 9. | Территориаль иҗтимагый үзидарәнең башка эшчәнлеге | |

**Кушымталар:** территориаль иҗтимагый үзидарә уставының күчермәсе;
территориаль иҗтимагый үзидарә тарафыннан башкарылган эшне раслый торган һәм аның казанышларын (хокукый актларның, шартнамәләрнең, сметаларның, программаларның, нигезләмәләрнең, түләү йөкләмәләренең күчермәләре, фотографияләр, гәҗитләрдә басмалар, гражданнар мөрәҗәгатьләре журналы, җаваплар күчермәләре, территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге турында халыкның һәм башка затларның бәяләмәләре) исбатлый торган өстәмә материаллар.

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә 4 нче кушымта

**«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында катнашуга территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең заявкаларын бәяләү критерийлары**

| Т/с | Критерий | Билгеләнгән балл |
|---|---|---|
| 1. | Территориаль иҗтимагый үзидарәнең халык мөрәҗәгатьләре белән эшләве (уңай хәл ителгән мөрәҗәгатьләр саны/гомуми мөрәҗәгатьләр саны х 100 %) | Иң зур күрсәткеч – 5 балл, иң кечкенә күрсәткеч – 1 балл |
| 2. | Территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчесенең киңәшмә (комиссияләр, советлар һ.б.) һәм җирле үзидарә органы каршындагы бүтән органнар составына керүе (күрсәтелгән органнар исемлеге) | Җитәкче нинди дә булса орган составына керсә – 1 балл, кермәсә – 0 балл куела |
| 3. | Территориаль иҗтимагый үзидарәнең физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлеге (үткәрелгән чаралар саны, чаралар исемлеге, раслый торган документлар – фотоматериаллар/ презентацияләр/ басмалар) | Иң зур күрсәткеч – 5 балл, иң кечкенә күрсәткеч – 1 балл |
| 4. | Территориаль иҗтимагый үзидарәнең мәдәни-массакүләм эшчәнлеге (үткәрелгән чаралар саны, чаралар исемлеге, раслый торган документлар – фотоматериаллар/ презентацияләр/ басмалар) | Иң зур күрсәткеч – 5 балл, иң кечкенә күрсәткеч – 1 балл |
| 5. | Территориаль иҗтимагый үзидарәнең социаль яктан ким категориядәге гражданнарга ярдәм итү эше (үткәрелгән чаралар саны, чаралар исемлеге, раслый торган документлар – фотоматериаллар/ презентацияләр/ басмалар).<br>Халыкның социаль яктан ким төркемнәре– керемнәре түбән дәрәҗәдә булган, социаль яктан якланмаган халык катламнары, гражданнар, гаиләләр.<br>Башлыча аларга өлкән ялгыз кешеләр, | Иң зур күрсәткеч – 5 балл, иң кечкенә күрсәткеч – 1 балл |

| | | |
|---|---|---|
| | инвалидлар, күп балалы һәм тулы булмаган гаиләләр, шулай ук туйдыручысын югалткан гаиләләр, керемнәре яшәү минимумыннан түбән булган затлар керә. | |
| 6. | Территорияне төзекләндерү һәм яшелләндерү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру (өмәләр, экологик акцияләр һәм яшелләндерү буенча башка чаралар үткәрү, аларның исемлеге, раслый торган документлар – фотоматериаллар/ презентацияләр/ басмалар) | Иң зур күрсәткеч – 5 балл, иң кечкенә күрсәткеч – 1 балл |
| 7. | Территориаль иҗтимагый үзидарә эш-чәнлеген һәм казанышларын массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту (басмалар һ.б. саны, басмаларның күчермәләре, интернет-ресурсларга сылтамалар, видеоматериаллар, башка раслый торган документлар) | Иң зур күрсәткеч – 5 балл, иң кечкенә күрсәткеч – 1 балл |
| 8. | Территориаль иҗтимагый үзидарәнең җәмәгать тәртибен саклауда һәм янгын куркынычсызлыгында катнашуы (ирекле халык дружинасы, тәртип саклау буенча җәмәгать пункты һ.б. белән уртак чаралар рәвешендә хезмәттәшлек итү, тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссияләр вәкилләренең янгын куркынычсыз-лыгы чараларында катнашуы, раслый торган материаллар) | Булса – 3 балл, булмаса – 0 балл |

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә 5 нче кушымта

Форма

**«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында катнашуга заявкаларны бәяләү кәгазе**

| Конкурс комиссиясе әгъзасының Ф.И.Ә.И. | |
|---|---|

| Заявка саны | Территориаль иҗтимагый үзидарә исеме | Оценка члена конкурсной комиссии (баллы) по критериям | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 (граждан нар мөрәҗә-гате) | 2 (җитәкченең киңәшмә һәм җирле үзидарә органнары каршындагы бүтән органнар составына кертелүе) | 3 (физик культура һәм спорт) | 4 (мәдәни-массакүләм эш) | 5 (халыкның социаль яктан ким катлам-нарына ярдәм итү) | 6 (төзеклән-дерү һәм яшелләндерү) | 7 (массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү) | 8 (тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары, ирекле халык дружиналары һ.б. белән хезмәттәшлек итү) | Заявка бәяләмә-сенең кушылма мәгънәсе (балл) |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| | | | | | | | | | | |

______________________________
конкурс комиссиясе әгъзасы имзасы

______________________
дата

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә 6 нчы кушымта

Форма

**«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында катнашуга заявкаларның йомгак бәяләмәсе нәтиҗәләре (заявкалар рейтингы)**

| Заявка саны | Ф.И.Ә.И. 1 конкурс комиссиясе әгъзасы заявкасы бәяләмәсенең кушылма мәгънәсе | Ф.И.Ә.И. 2 конкурс комиссиясе әгъзасы заявкасы бәяләмәсенең кушылма мәгънәсе | Ф.И.Ә.И. 3 конкурс комиссиясе әгъзасы заявкасы бәяләмәсенең кушылма мәгънәсе | Ф.И.Ә.И. ... конкурс комиссиясе әгъзасы заявкасы бәяләмәсенең кушылма мәгънәсе | Заявканың гомуми кушылма бәяләмәсе 6 төркем = Σ (2, 3, 4, 5, …төркем) | Заявканың йомгак бәяләмәсенең уртача арифметик мәгънәсе (7 төркем = 6 төркем/ бәяләүдә катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары саны) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Конкурс комиссиясе рәисе __________________ /__________________________/

Ф.И.Ә.И.

____________________

дата

Конкурс комиссиясе секретаре __________________ /___________________________/

Ф.И.Ә.И.

____________________

дата

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә 7 нче кушымта

**Грантларны төркемнәр һәм урыннар буенча бүлү**

| Урын | Грантлар саны | | | |
|---|---|---|---|---|
| | гомуми | 1 төркемдә | 2 төркемдә | 3 төркемдә |
| I урын | 30 | 11 | 11 | 8 |
| II урын | 20 | 8 | 7 | 5 |
| III урын | 20 | 7 | 7 | 6 |
| IV урын | 25 | 8 | 9 | 8 |
| V урын | 25 | 8 | 8 | 9 |
| Барлыгы | **120** | **42** | **42** | **36** |

______________________